Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

23 март, 2021 ел № 11

«2016-2020 елларга Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2016 елның 15 мартындагы 7А номерлы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Кощаково авыл җирлеге Уставы нигезендә Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге башкарма комитеты карар кабул итте:

1. Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 15 мартындагы 7А номерлы карары белән расланган «2016-2020 елларга Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2021-2023 елларга Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасы (алга таба - муниципаль Программа);

2. Әлеге карарны Кощаково авыл җирлегенең Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н. Саттарова